**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

25.03.2016 Яр Чаллы № 798

Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 201 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урын, торак урыны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»2015 елның 25 мартындагы 269 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2011 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитет Җитәкчесенең 2012 елның 5 июлендәге 2104 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Расларга:

Билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (1 кушымта).

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 10 апрелендәге 1476 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.В.Асылгәрәев